КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 ноябрь г.Казань № 985

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 11 ноябрь, 855 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 1 февраль, 45 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелмәгән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына, 12 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениеләргә язмача рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелә.

12.2. Учреждениеләр, Учреждениеләрнең вазыйфаи затлары, Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча бердәм портал йә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча төбәк порталы буенча җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Учреждениеләргә, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына кергән шикаять теркәлгән көненнән унбиш эш көне эчендә, ә Учреждениеләрнең гариза бирүчедән документлар кабул итүдән һәм җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре хакында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча нигезле җавап җибәрә.

12.6. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгәндә, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәҗбүри медицина иминиятләвенең база программасына керми торган авыруларда медицина тернәкләндерүе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 13 май, 280 нче карары белән расланган Мәҗбүри медицина иминиятләвенең база программасына керми торган авыруларда медицина тернәкләндерүе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, 12 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениеләргә язмача рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына

– бу Стандартның 1 бүлегендәге 1.1 нче пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар тарафыннан, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына бу Стандартның 1 бүлегендәге 1.1 нче пунктның 2 – 4 нче пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар тарафыннан бирелә.

12.2. Учреждениеләр, Учреждениеләрнең вазыйфаи затлары, Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча бердәм портал йә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча төбәк порталы буенча җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Учреждениеләргә йә югары органга кергән шикаять теркәлгән көненнән унбиш эш көне эчендә, ә Учреждениеләрнең гариза бирүчедән документлар кабул итүдән һәм җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре хакында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча нигезле җавап җибәрә.

12.6. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгәндә, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелгән махсус медицина ярдәме (югары технологияле медицина ярдәменнән тыш) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты

стандартын раслау турында» 2017 ел, 12 декабрь, 977 нче карары белән расланган Мәҗбүри медицина иминиятләвенең нигез программасына кертелгән махсус медицина ярдәме (югары технологияле медицина ярдәменнән тыш) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, 12 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) Учреждениеләргә язмача рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелә.

12.2. Учреждениеләр, Учреждениеләрнең вазыйфаи затлары, Учреждениеләр җитәкчеләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Учреждениенең рәсми сайты, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча бердәм портал йә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча төбәк порталы буенча җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә бирелергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Учреждениеләргә, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына кергән шикаять теркәлгән көненнән унбиш эш көне эчендә, ә Учреждениеләрнең гариза бирүчедән документлар кабул итүдән һәм җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуына яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре хакында язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча нигезле җавап җибәрә.

12.6. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять җавап биргәндә тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгәндә, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин